Җамалетдинова, Ф. "Алда - ак кәгазь, кулда - каләм, җанда - кеше язмышы" / Ф. Җамалетдинова; [әңгәмәдәш] Р. Гасыймова // Мәйдан. – 2025. – №3 (280). – Б. 113-117.

# Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА: «Алда – ак кәгазь, кулда – каләм, җанда – кеше язмышы»

***Фирүзә Җамалетдинованы татар дөньясы иң элек шагыйрь дип таныгандыр. Аннары инде шигъри күңелле язучы дип. Мин әдәбият галиме түгел, әмма гади укучы буларак шуны әйтә алам: аның әсәрләренә ниндидер романтика хас. Геройлары һәрвакыт язмышны җиңеп, «очарга талпынып» кала кебек.***

***Без Фирүзә ханым белән бүген газаплы да, рәхәт тә булган иҗат турында сөйләшеп утырдык.***

## ПРЕМИЯЛӘР ҮЗ-ҮЗЕҢӘ ЫШАНЫЧНЫ АРТТЫРУ ӨЧЕН КИРӘК

**– Фирүзә ханым, бу көннәрдә сез күркәм юбилеегызны билгеләп үтәсез. Һәм канәгатьлек хисе беләндер дип ышанам, чөнки язучы булып танылып, Саҗидә Сөләйманова, Фатих Хөсни, Һади Такташ әдәби премияләрен алу бик зур дәрәҗә бит. Әгәр балачакка – мәктәп елларына кайтсак, менә шушы өч зур әдипнең кайсының иҗаты күңелегезгә аеруча якын булды икән?**

– Һичшиксез, өчесе дә якын иде. Такташны күпме укысаң да ялыкмыйсың, гел яңа яктан ачыла торган бөек шагыйребез ул. Мәктәп программасында аның иҗаты шактый урын били иде. Фатих Хөсни исемендәге премия исә хикәяләр өчен тәгаенләнгән. Миңа ул 1913 елда дөнья күргән «Хикәяләр» китабым өчен бирелде. Бу премиягә язучыларыбыз ел да лаек булып торалар. Димәк, хикәя жанры безнең әдәби мәйданда төшеп калганнардан түгел.

Әти район кибетеннән Саҗидә Сөләйманованың «Кызыл каурыйлар» китабын алып кайтып биргән бәхетле көнемне хәтерлим әле мин. 1976 ел иде. Менә шулай язасы иде, дип уйлый идем, ләкин күпме язарга тырышсам да Саҗидә апача килеп чыкмый. Әле дә шул елларны сагынганда аның китапларын кулыма алам. Саҗидә Сөләйманова премиясе төп һәм кызыксындыру премияләренә бүленә. Миңа кызыксындыру премиясен «Догалы корт» исемле проза китабым өчен бирделәр.

**– Нигә кызыксындыру премиясе генә булды икән? Минем яраткан китабым бит ул!**

– Ничек булса да, зур истәлек инде ул. Бик аз язучы, шагыйрьдә генә ул кызыксындыру премиясе: Нияз Акмал, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, Айгөл Әхмәтгалиева, Луиза Янсуар, Гөлүсә Батталовада, миндә. Мондый талантлы каләмдәшләрем янәшәсендә торуым белән дә бәхетлемен. Чаллыда яшәгәндә үк Саҗидә апа турында «Сөембикә» журналына бик матур язма бастырган идем. Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә, күңелем кушканча, аның «Сайланма әсәрләр»енең төзүчесе, редакторы булдым. Әлбәттә, улы Әнвәр, килене Асия ханым белән киңәшләшеп эшләдек. Шигърият яратучыларга бик күркәм җыентык бүләк иттек. Саҗидә апаның рухы шат булсын!

Премияләр, бүләкләр язучыга үз-үзенә ышанычны арттыру өчен кирәк кебек. Күңел үсеп китә...

Нигәдер, минем гел язасым килде. Язучылыкның ни икәнен бик белеп тә бетермәгәнмендер. Балачакта күңелнең куанычлары күп була, менә шуларны уртаклашасы килү теләге туа иде. Кәгазьгә төшерәсе... Ә кәгазьгә төшерүнең ни дәрәҗәдә кыен икәнлеген чамалагач, үз-үзең белән көрәшә башлыйсың. Барыбер язачакмын, дисең. Әле дә шулай ул. «Иҗат газабы» дигән гыйбарә юктан гына тумагандыр. Чөнки газапны кичеп чыга алсаң, аның аръягында шатлык-куаныч көтеп тора. Яхшымы, яманмы, бернигә карамыйча, күңел рәхәтлек хисләре кичерә.

**– Шулкадәр дөрес тасвирладыгыз!**

– Аннан, балачакта безнең өчен газета-журналлар чыга, алар балалар иҗатын даими бастыралар иде. Казанга семинарларга чакыралар. Зур язучыларны күреп, аларның фикерләрен тыңлап кайту үзе үк иҗат юлыннан тайпылмыйча, булдыра алганча язып яшәргә мөмкинлек тудыра сыман тоела. Конкурслар гел оештырылып торды. Җиңүчеләрне Илдар Юзиев, Шәүкәт Галиев, Рәдиф Гаташ кебек күренекле шагыйрьләребезнең култамгалары салынган китаплар белән бүләклиләр. Болар барысы да бала күңеле өчен бик олы вакыйга иде инде.



Университетта бергә укыган төркемдәшләре белән

## ЖУРНАЛИСТИКА – ТОРМЫШНЫ ӨЙРӘНҮ МӘКТӘБЕ УЛ

**– Язучыларның күбесе татар теле-әдәбияты факультетын тәмамлаган була. Безнең кебек журналистика тәмамлаучылар, гадәттә, әдәби иҗатка бик кереп тә китә алмый сыман. Нигә шулай икән ул? Менә сез дә бит...**

– Әйе, мин дә Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамладым. Мөхәммәт Мәһдиев, Хатип Миңнегулов, Флера Сафиуллина, Зәет Мәҗитов, Вахит Хаков, Диләрә Тумашева, Фәһимә Хисамова, Шәйхи Садретдинов кебек танылган язучылар, галимнәр иде безнең укытучыларыбыз. Әдәбиятның, туган телебезнең серенә алар төшендерде. Сүзгә җаваплы карарга өйрәттеләр. Язучы тудырган дөньяның ни дәрәҗәдә тәэсир көченә ия булуына да укыганда төшендек. Әсәрдә укучыга да шул мохиттә яшәп алырлык мөмкинлекләр булырга тиешлеген белдек. Кәефне кырган, баштан ук күңел кабул итмәгән әсәрне укып

булмый. Мөхәммәт Мәһдиев без – татар мәктәбеннән килгән авыл балаларына хәтта совет әдәбиятын да татарча укыды. В. Быков, В. Распутин, В. Астафьев, М. Байҗиев кебек зур әдипләрнең иҗатына мәхәббәт орлыклары салды. Һәм без укыган чорда тәрҗемәчелек эше бик югары дәрәҗәдә куелган булган. Бик күп китаплар татар телендә басылган. Татар укучысына хәтта дөнья әдәбияты белән танышыр мөмкинлек тудырылган. Аллаһыга шөкер, бу эшне хәзер Ркаил Зәйдулла, үз кулына алып, янә җанландырып җибәрде.

Ә журналистикага килгәндә, миңа ул да ят шөгыль түгел – Чаллыда яшәгәндә «Таң йолдызы» газетасында, «Мәйдан» журналында, Казанга күчкәч, «Ватаным Татарстан» газетасы, «Казан утлары» журналында эшләдем. Күпме кеше белән очрашасың. Һәрберсенең үз язмышы. Кешеләрнең журналистка бөтен тормышларын сөйлисе килә. Тыңларга өйрәнәсең. Төзелеш газетасында эшләгәндә төзүчеләр бик актив иде. Үзләре дә гел язып тордылар. Үзебез дә эш кешеләре турында күп яздык. Алардагы рухи ныклык, эш сөючәнлеккә, тормышны шулкадәр яратуларына исем китеп карый идем.
Бер тапкыр яңа төзелеп килүче йортка, буяучылар бригадасы белән очрашуга бардык. Безнең киләсене белмиләр. Кышкы шактый суык көн иде. Батарейларга сизелер-сизелмәс җылы биргәннәр. Барыбер бүлмәләргә җылы төшмәгән. Подъезд ишеген ачуга, егылып китәрлек буяу исе борынга бәрелә. Һәм кайсыдыр каттан бик моңлы җыр ишетелә:

*Күпме карасам да карап туймыйм*
*Идел буе каеннарына...*

Башкалар да кушылып куйгалый. Көлешә-сөйләшә эшлиләр. Борыны салынган беркемне күрмисең. Алардагы оптимизм! Шушы кешеләр янында тәрәзәдән карыйсың: бөтен нәрсә икенче төрле күренә: төсләр җетерәк, дөнья матуррак. Төзүчеләр дә җир өстенә матурлык тудыручылар шул дисең. Алар яныннан кайткач та өс киемнәреннән берәр атна буяу исе килеп йөри. Моны үзең сизмисең дә, хезмәттәшләр әйтә.

Гомумән, журналистика – тормышны өйрәнү мәктәбе инде ул. Тормышны белми торып, әдәби әсәр язу мөмкин түгел. Журналистика да, әдәбият та, беренче чиратта, намуслы булуны таләп итә. Икесендә дә алда – ак кәгазь, кулда – каләм, җанда – кеше язмышы дигәндәй... Аларга җаваплы карыйсы.

## ИҖАТ КЕШЕСЕ СИГЕЗГӘ ЭШКӘ КИЛЕП ҖИТӘ АЛМЫЙ

**– Чаллыда яшәүче иҗат кешеләренең Казанга омтылуы – табигый күренеш бугай инде ул. Сез ул яктан бәхетле – Казанга күчтегез. Тормышыгызга, иҗатыгызга ничек йогынты ясады Казан? Һәм, гомумән, провинциядә яшәү язучының үсешен тоткарлыймы бүген, ничек уйлыйсыз?**

– Казанга күчүебезгә егерме елга якын. Чаллыда егерме елдан артык яшәдек. Мин ике шәһәрне дә яратам. Чаллыга баргач, таныш урамнарны, проспектларны күзләрем күреп туялмый. Җир өстендә шулкадәр үз, шулкадәр якын, таныш шәһәр булыр икән, дип гаҗәпләнәм. Без киттек тә соң, туганнарыбыз, дусларыбыз, танышларыбыз анда калды. Аралашып торабыз. Шуңа Чаллыдан аерылганым да юк.

Ә Казан – башкалабыз инде ул. Кайда яшәвеңә карамастан, үзенә тарта. Ул тарту көчен аңа Аллаһы Тәгалә Үзе салгандыр кебек. Туган ягым – Чүпрәлем дә моннан якынрак. Әлһәмдүлилләһ, әнием исән-сау. Әлбәттә, иҗат кешесе өчен Казанда мөмкинлекләр күбрәк. Театрлар, концертлар, иҗади очрашулар... Эшең дә бөтен татар дөньясына бәйләнешле. Масштаблырак. Монда да дусларым күп. Бергә укыган сабакташларым мине эшкә чакырып кына тордылар. Рәхмәт яусын һәммәсенә! Алар янәшәсендә миңа бер дә кыен булмады. Чаллыны да провинция

дип атыйсым килми Хәзер бит Чаллы–Казан арасы – ике сәгатьлек юл. Эшләгәндә Чаллы язучыларын көн дә диярлек күреп тора идем. Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә Чаллыда яшәп иҗат итүче күпчелек язучыларның китапларының редакторы үзем булдым. Язучы иҗаты аның кайда яшәвенә һич бәйле түгелдер. Авылда яшәп тә Тукай премиясе алган зур әдипләребез бар безнең. Иң мөһиме, кайда яшәсә дә язучы үзен ирекле хис итәргә тиеш. «Ирекле» дигәннән, «Мәйдан»да эшләгән чак искә төште. Факил Сафин шулкадәр иҗади коллектив туплады: Рәшит Бәшәр, Айгөл Әхмәтгалиева, Амур Фәләх, Рафис Могыйнов, Сания Хәйретдинова, Лариса Яруллина, Гөлшат Илалетдинова һ.б. – 22 кеше идек кебек. Ә иҗадилыкны әйтеп кенә аңлата торган түгел. Журнал искиткеч югары дәрәҗәдә чыгып килде. Бик рәхәт итеп, яратып эшләдек. Чөнки моның нигезендә Факил әфәнде тарафыннан иҗат кешесенең ирекле булырга тиешлеген аңлау ята иде.

Без бит хакимият бинасында утырабыз. Эшкә пропуск белән генә кертәләр. Иртән сигезгә килеп җитә алмыйбыз. Йә биш минутка, йә ун минутка соңга калабыз. Әлбәттә, ишек төбендә безнең пропускларны җыеп алып калалар. Факил әфәнде аларны юллап кадрлар бүлегенә менеп китә. Иҗат кешесенең эш вакыты сигез сәгать белән генә чикләнмәвен шактый аңлатырга тырышып карады ул. Ахырда: «Йә сигезгә килеп җитегез инде, җәмәгать, йә тугыздан соң килегез», – дип куйды. Бу үзе үк ирекле иҗат кешесе сүзе түгелме?! Чаллыда яшәп иҗат иткән бик күп язучыларның иҗади үсешендә Факил Сафин белән Рәшит Бәшәрнең дә өлеше бар. Рәхмәт аларга! Ә «Мәйдан» журналының әле дә дәрәҗәсен саклап, матур итеп эшләп килүенә бик куанам. Татар халкының рухи дөньясын баетып-тулыландырып, чорлардан чорларга күчеп яшәргә язсын!

**– Амин, шулай булсын! Факил абый, дигәннән, безгә дә аның белән озак еллар бергә эшләргә насыйп булды. Кул астындагы хезмәткәрләренә хөрмәт белән карый, юк-бар сәбәп табып, эшләргә комачауламый торган җитәкче ул Факил абый. Ә бит җитәкчеләр арасында комачаулаучылар да була. Фирүзә ханым, сез поэзиядә дә, прозада да бердәй иҗат итүчеләрнең берсе. Ә менә драматургиягә әле кереп тә карамадыгыз кебек. Нигә икән? Бу жанрдагы әдәби әсәрләргә югыйсә ихтыяҗ зуррак та бит – татар театрлары бик актив эшли, яңа әсәрләр гел кирәк булып тора, кызыклы тәҗрибәләр кулланыла. Һәм нәкъ менә театр сәнгатендә язучы иҗаты тиешенчә бәяләнә дип тә ишетеп киләбез бит инде без, дөрес булса.**

– Драматургия димәктән, минем өлкә микән соң ул? Бу хакта бер дә уйлап та караганым юк икән. Шулай да, театрларыбызны бик яратам. Бу өлкәдәге сәнгатебезне үз юлыннан, дөрес итеп алып баралар дип уйлыйм. Хәзер бит тамашачы да төрле, кемгә җиңел, җыр-биюе булса җитә, кемгәдер тирән, тарихи, тәэсирле әйбер кирәк. Театрларда һәр төркем өчен ярашлы спектакльләр бар. Үземә килгәндә, яшь режиссер Айдар Җәббаров «Хуш авылым» исемле спектакль куйды. Әле дә бара. Туфан Миңнуллин һәм минем ике хикәямне бер спектакль нигезенә алып сәхнәләштергән иде ул. Театрда әдәбиятны яратучы Илдус Әхмәтҗанов бар, мәрхүм Хәлим абый Җәләй әдәби мәгълүматлы кеше иде. Кайда, нинди әсәрең басылса да, йә үзе килеп җитә, йә шалтыратмый калмый. Алар тәкьдиме белән керткәндер Айдар. Шул спектакльгә кунак итеп чакыргач, аптырап киттем. Беркайчан да, берни дә биргәнем юк бит, дим. Һәм бик яратып кайттым. Айдар уйланырга мәҗбүр итәрлек әсәрләр куя. Шуңа мин аны иң өметле яшьләребездән саныйм.

**ЯЗУЧЫ – СӘЯСӘТЧЕ ТҮГЕЛ, СӘЯХӘТЧЕ**

**– Бездә, милли мәнфәгатьләр турында сүз башлауга, татар язучыларын искә төшерү гадәткә кергән – татар язучысы туган тел өчен җаваплы дияргә яратабыз без. Ә менә сез ничек уйлыйсыз, язучы бүгенге шартларда милли мәнфәгатьне кайгырту максаты беләнниләр эшли ала икән?**

– Шулай инде, язучыга күпчелек очракта сәясәтче итеп карыйлар. Ләкин язучы сәясәтче түгел. Теге яки бу чордагы сәясәтне күрсәтүче генә. Язучының үзе тудырган коточкыч катлаулы һәм искиткеч гади, кызыклы дөньясы бар. Ул яртылаш чынбарлыктан, яртылаш фантазиядән гыйбарәт. Милләтнең мәхәббәтен дә, нәфрәтен дә язучы әсәрләренә сала. Халкыңны башкалар шушы әсәрләр аша таный. Омтылышлары, уйлары да үз милләтенеке. Димәк, туган тел өчен җаваплы түгел, дию дөреслеккә туры килмәс. Язучы ул – ана сөте белән кергән телне сакларга ярдәм итүче. Туган телендә әсәр ишетеп үскән, татарча укыган бала туган телендә яши, туган телендә уйлый. Мин монысын үз улымнан, туганнарымның балаларыннан чыгып та әйтәм. Ә үсеп җиткәч кенә татарча сөйләшергә өйрәнүгә калгач, булмый инде ул. Ис тою, төсләргә соклану, тәм тату кебек төшенчәләр кешегә туганда ук салынган була. Туган телнең дә үз исе, тәме, төсләре бар. Ана сөте белән кермәгән, ягъни өйрәнгән телдә кеше күбрәк мәгънә белән генә эш итә. Хәтер бары мәгънәне, акыллы фикерләрне тотып бара... Ә милли мәнфәгатьләрне кайгырту бүгенге вазгыятьтә һәр гаиләнең үзенә бәйле булып калды түгел микән? Гаилә төшенкелеккә бирелмичә баласын шушы чор аша алып чыга алса, киләчәк, бәлки, башкача булыр... Өмет белән яшәр өчен дә безгә бик күп тырышырга кирәк. Бала рухын саклардык мәктәпләребез, мәчетләребез, әз булса да, бар. Язучыларыбыз да язудан туктаганы юк. Мәктәпләргә, балалар бакчаларына очрашуларга йөреп торалар. Тик нишләп була? Төгәл генә әйтә дә алмыйм. Чирлене чебен талар ди... Кысла кебек инде без: бер адым алга, ике адым артка дигәндәй... Коръәндә «Әнфәл» сүрәсендә: «Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртми, ул кавем үзләрен үзгәрткәнгә чаклы», – дип язылган. Ана телен дә безгә нигъмәт итеп биргән бит Ул, кадерен белмәүчеләрнең күбәюе шушы нигъмәтне юкка чыгу куркынычы астына куя... Татар теле укытучыларының вазгыятькә бәйле хәле турында мин «Кешенекен алу – язык» дигән хикәямдә язып чыктым.

**– Сезне язучы буларак бер генә җөмлә белән характерларга кушсалар, мин: «Бүгенге көн турында язучы», – дип җавап бирер идем. Чыннан да, күп язучыларга артка карап, элекке истәлекләрне, гыйбрәт алырлык хәлвакыйгаларны барлау-тасвирлау хас. Алга баручы арбада артка карап утыру, ягъни мәсәлән. Ә менә сез һәрвакыт бүгенге көн, бүгенге көнгә хас күренешләр, проблемалар турында язасыз. Шул ук «Догалы корт»ны алсак та, мисал өчен. Язганнарыгыз вакыт сынавын үтә алмас, искерер дип курыкмыйсызмы? Гомумән, әдәби әсәр искерергә мөмкинме ул?**

– Әйе, мин бүгенге көн турында язам, күпчелек очракта, бүгенге үткәннәр белән параллель бара. Әгәр дә әсәр кеше күңеле турында икән, ул бер чорда да искерми дип уйлыйм. Намус-намуссызлык, яхшылык-яманлык, мәхәббәт-нәфрәт, гаделлекялган һ.б. төшенчәләр моннан мең еллар элек тә яшәгән, моннан соң да шулай ук калачак. Әгәр дә теге яки бу идеологиягә кушылып, аңа дан җырлау ягына бассаң, әлбәттә, әсәр искерәчәк. Без бит коммунизмга барып җитә язып, капитализмга таба борылып киткән буын. Әбиләр әйтмешли, «падишаһ»ларны да күп алыштырдык. Торгынлыгын да, үзгәртеп коруларны да, үзгәрешләрне дә күп күрдек. Язучы җәмгыятьтән башка яши алмый әлбәттә, тик системаны мактау да, хурлау да аның бурычы түгел, ул күрсәтергә генә бурычлы. Хәер, хәзер әдәбият та башкарак юнәлеш алды кебек. Дөнья әдәбиятында бу бигрәк тә сизелә. Югары сәнгать дәрәҗәсенә ирешү мөмкинлекләре күбрәк булган сюрреалистик, модернистик әдәбиятны алга чыгару өчен тырышалар сыман. Ә элеккеге классик әсәрләргә

карасаң, алар, беренче чиратта, гади, аңлаешлы булган, анда һәркем үзен табарга тырышкан, тормышындагы вакыйгалар белән тәңгәллек эзләгән, әсәрне укып чыккач, язучы укучының хәленә кергәндәй тоелган, шуннан ике як та канәгать калган.

Әсәрләрем әдәбияттагы яңалыкларга ни дәрәҗәдә бәйледер, анысын билгеләү галимнәр эше. Тик бер нәрсәне беләм: мин туган халкым өчен язам. Аның әрнүләре дә, куанычлары да йөрәгем аша үтә. Аларны үз вакытында тотып, күрсәтеп калырга өлгерү – монысын уңышым дип саныйм. Әсәрләремә Аллаһы кушканча, кеше җаны өчен хәерлесен салырга тырышам.

**– Минем үземә иң ошаган әсәрегез – «Буранда» хикәясе. Сез сурәтләгән герой шундый зур ярату, шундый зур сабырлык белән авыру баласын тәрбияли. Укучыда рухи көч уята торган әсәр дип саныйм мин аны. Бу хикәянең идеясе ничек туды? Прототиплары бармы?**

– «Буранда» хикәясе, алда әйткәнемчә, чынбарлык белән язучы фантазиясе кушылудан туган хикәя. Мин аны үзем дә яратам. Кешеләр рухи яктан нык булсалар, балалар йортлары да, картлар йортлары да ачылмас иде. Ана дигән бөек исемгә лаек олы йөрәкле, язмыш сынауларын шушы олы җаны белән җиңеп барган авыл карчыгын тасвирладым мин анда. Шушындый көчле рухлы затлар безнең милләттә аз түгел бит.

**– Хатын-кызга үзен бәхетле хис итәр өчен эш кенә түгел, гаилә дә кирәк. Гаиләгез турында да сөйләшик әле, Фирүзә ханым.**

– Әйе, гаиләм – минем төп терәгем. Миңа өемдә рәхәт. Ирем Рамил белән бер ул үстердек. Хәзер инде икебез дә лаеклы ялда. Аллаһы Тәгаләгә якынаерга тырышып, намазлы-догалы тормышта яшәп ятабыз. Әлһәмдүлилләһ! Улыбыз Наил генетика юнәлешеннән китте. Биология фәннәре кандидаты. Аның белән үз телебездә сөйләшәбез. Ана сөте белән кергән туган тел беркайчан да онытылмый икән ул.

**– Язучы буларак танылгач, иң кыены – торгынлык чорларыдыр, мөгаен. Әдәби иҗат өчен материал табу кыен түгелме? Без бит барыбер бертөслерәк – артык тыныч диимме – яшибез. Сәяхәттән сәяхәткә йөрсәк, бәлки, яңа темалар туып кына торыр иде.**

– Сәяхәт итәргә бик яратам. Тик мин күрмәгән илләр, мин барып җитмәгән җирләрнең исәбе-хисабы юк. Дөнья күрәсе килә, әлбәттә. Кая барсам да, үз халкымның бер вәкиле булып калам. Бервакыт Африкада – Туниста безне ресепшендагы кызлар елмаеп, гарәпчә нидер әйтеп каршыладылар. Мин аларның җөмләләренә төшенмәсәм дә: «Исән-имин килеп җиттегезме?» – диюләрен тоемлап аңладым. «Әлһәмдүлилләһ, рәхмәт, бик әйбәт килдек», – дип үзебезчә җавап бирдем. Шушы бер җөмлә җитте, безне иң тыныч, иң зур, чиста, матур бүлмәгә урнаштырдылар. Инглизчә әйткәннәрен арабыздагы яшь кыз тәрҗемә итте: «Болар мөселманнар, яхшы бүлмәгә урнаштырыгыз, дип әйттеләр», – ди. Бер төркем юлдашларыбызга әллә ничә тапкыр бүлмәдән-бүлмәгә күчеп йөрергә туры килде. Йә инглизчә генә сөйләшкәннәрдер инде... Берсендә сулап булмый юеш, дип зарландылар, икенчесе тараканлы һәм тавышлы булып чыкты... Төркия күңелемә якын. Ризыклары хәләл. Анда үз республикаңдагы кебек иркенләп, автобус белән тирә-юньдәге шәһәрләргә барып кайтырга җайлы. Халык арасында йөрисең. Аннан, үз илебез дә чиксез зур бит. Төньяк Кавказда ял итү ошый. Анда күпчелек халык белән татарча аңлашып була. Балкарлар, карачайлар, уйгырлар, кумыклар гел безнеңчә сөйләшә. Базарларда, нигездә, төрки халыклар. Татарларны бик хөрмәт итәләр. Туганнарыбыз, дип, әйберне бик арзан хакка да биреп җибәрергә мөмкиннәр. Республикабыздагы хәлне дә белеп торалар. Хәтта безнең куанычны үзләренеке саныйлар. Бер тапкыр бассейнда бер төркем ир-атлар: «Афәрин! «Ак Барс» җиңде!» – дип куанышып, кычкыра-кычкыра

сөйләшәләр. «Татарлар мәллә соң болар?» – дим иремә. Алар балкарлар һәм кумыклар булып чыкты. Аннары аралашып киттек инде. Бергә сәяхәткә йөргән дусларым кайчак: «Синең татарчаңны бөтен илдә бөтен кеше аңлый», – диләр. Аңлыйлар шул. «Татарга тылмач кирәкми» дигән әйтемне чорлар тудыргандыр. Әйе, сәяхәтләр яшәр өчен дә, иҗат өчен дә көч бирә. Сәламәтлек һәм илгә тынычлык кына бирсен Раббыбыз!

**Ризидә ГАСЫЙМОВА сөйләште**

***(Фотолар Ф. Җамалетдинова архивыннан.)***